МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛАГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от “07” 10.2015 №390

Казан

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе турында

“Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсенең 3 пунктын үтәү йөзеннән һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүне анализлаганда бердәм карашны тәэмин итү максатыннан боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен расларга.

2. Оештыруны үстерү бүлеге мөдире Л.Г. Хәкимовага гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлауны (алга таба – анализ) елга ике мәртәбә үтәргә, яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 15 нче числосына кадәр.

3. Мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат секторы төп киңәшчесе И.Р. Калимуллинга Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгынының рәсми сайтына, яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 15 нче числосыннан да соңга калмыйча, анализны урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлүен контрольдә тотуны эшләр белән идарә итүче А.Р. Галимбековка йөкләргә.

Министр Л.Р. Сафин

Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгының
2015 елның 7 октябрендәге
390 номерлы боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе

1. Әлеге Тәртип "Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсен үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында (алга таба – Министрлык) гражданнар һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләрне (алга таба – мөрәҗәгатьләр) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау Министрлыкның оештыруны үстерү бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан электрон документ әйләнеше белешмәләре һәм әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә тапшырыла торган мәгълүмат нигезендә башкарыла.

3. Министрның, министрның урынбасарларының, эшләр белән идарә итүченең (алга таба – Министрлык җитәкчелеге, гражданнарны шәхсән кабул итү буенча вәкаләт бирелгән затлар) шәхсән кабул итүе барышында ирешкән мәгълүматлар турында мәгълүмат Бүлеккә гражданнарны Министрлык җитәкчелегенә шәхсән кабул ителүгә теркәүче белгечләр тарафыннан тапшырыла.

4. Әлеге Тәртипнең 3 пунтында күрсәтелгән мәгълүмат Бүлеккә җаваплы хезмәткәрләр тарафыннан яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 12 нче числосына кадәр тапшырыла.

5. Анализ үткәргәндә килгән, бер адрестан икенче адреска җибәрелгән һәм карап тикшерелгән язмача мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ әйләнеше рәвешендәге мөрәҗәгатьләрнең саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында, шәхсән кабул итү барышында кабул ителгән гражданнарның саны, гражданнарны шәхсән кабул итүгә вәкаләт бирелгән затлар һәм урынга чыгып шәхсән кабул итү турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү нәтиҗәсендә кабул ителгән чаралар турындагы мәгълүмат, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый һәм башка төрле актлар (булган очракта) турындагы мәгълүмат өйрәнелә.

6. Бүлек мөдире әлеге Тәртипнең 2 нче һәм 3 нче пунктларында күрсәтелгән гомумиләштерүне һәм мәгълүмат анализын яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 15 нче числосына кадәр үти.

7. Мөрәҗәгатьләрнең анализы мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат секторына Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру өчен җибәрелә. Анализ

Министрлыкның рәсми сайтында яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 20 нче числосыннан да соңга калмыйча урнаштырыла.

8. Министрлыкта гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләр анализы Министрлыкның рәсми сайтындагы (http://mindortrans.tatarstan.ru/) ирекле файдалану өчен ачык мәгълүмат булып санала.